**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

06.05.2021

№ 8

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге
җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүдә
вәкаләтләрнең бер өлешен кабул иту турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешенә һәм 14 статьясындагы 1 өлешнең 20 пунктына кертелгән үзгәрешләр, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 19.04.2021 33 номерлы карары, «Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2020 елның 01 октябрендәге 8 номерлы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы Карар итте:

1.Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Кабул итәргә:

- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү һәм раслау;

- җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм раслау;

- җирлекне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау һәм үзгәрешләр кертү.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар бер елга билгеләнә һәм ул басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Н.Габдрахманов